КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 август г.Казань № 708

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче; 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы; 2015 ел, 14 май, 341 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2015 ел, 17 ноябрь, 862 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 781 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет хакындагы бертип нигезләмәгә, 5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«5.12. Иҗтимагый совет карары буенча Иҗтимагый совет утырышларына Иҗтимагый совет карап тикшерә торган мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен башкарма органнар, коммерциягә карамаган оешмалар, фәнни учреждениеләр вәкилләре, экспертлар, башка белгечләр һәм гражданнар чакырылырга мөкин.

Иҗтимагый совет әгъзалары булмаган массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре Иҗтимагый совет чакыруы буенча Иҗтимагый совет утырышларында катнаша ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин